МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 148/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«08» 09 2015

**Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында алар буенча вазифаи бурычларны башкару дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган, аларга билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында**

2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясының 3 өлеше, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2015 елның 02 июнендәге “Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак коммуналь хуҗалык министрлыгында штат расписаниесе структурасын үзгәртү һәм раслау турында” 79/о номерлы боерыгы нигезендә **боерык бирәм:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында алар буенча вазифаи бурычларны башкару дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган, аларга билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген расларга.

2. Юридик бүлеккә (Латыйпова Э.Ю.) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2014 елның 05 августындагы “Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының алар буенча вазифаи бурычларны башкару дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган, аларга билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында” 93/о номерлы боерыгын көчен

югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

ОТДЕЛ
РЕГЛАМЕНТА
И КОНТРОЛЯ
№1

КОПИЯ ВЕРНА
Оригинал документа хранится
в отделе регламента и контроля
Министерства строительства,
архитектуры и ЖКХ РТ

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалык
министрлыгының
2015 елның “_08_”___09___
№_148/0_ боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында алар буенча вазифаи бурычларны башкару дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган, аларга билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге

Эшләр белән идарә итүче;
кадрлар сәясәте бүлеге башлыгы;
бюджет үтәлеше, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы;
юридик бүлек башлыгы;
мобиль әзерлек, гражданлык оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм серлелек режимы секторы җитәкчесе;
мобиль әзерлек, гражданлык оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм серлелек режимы секторының әйдәп баручы киңәшчесе;
дәүләти, максатчан һәм тармак программаларын формалаштыру идарәсе башлыгы;
җыелма-аналитик бүлек башлыгы;
мәгълүматлаштыру секторы җитәкчесе;
төзелеш комплексын үстерү идарәсе башлыгы;
төзелеш материаллары һәм технологияләре сәнәгате бүлеге башлыгы;
архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы;
архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең шәһәр төзелеше сәясәте бүлеге башлыгы;
архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең шәһәр төзелеше сәясәте бүлеге башлыгы урынбасары;
архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең территорияләрне планлаштыру һәм төзү бүлеге башлыгы;
архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең архитектура бүлеге башлыгы;
шәһәр төзелеше эшчәнлеген контрольдә тоту бүлеге башлыгы;
эксплуатация һәм ТКХ программаларын гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы;
эксплуатация һәм ТКХ программаларын гамәлгә ашыру идарәсенең ТКХ объектларын эксплуатацияләүне һәм төзекләндерүне мониторинглау бүлеге башлыгы;
эксплуатация һәм ТКХ программаларын гамәлгә ашыру идарәсенең торак хуҗалыгында программаларны формалаштыру һәм гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы;
эксплуатация һәм ТКХ программаларын гамәлгә ашыру идарәсенең ТКХ үзгәртеп кору һәм модернизацияләү бүлеге башлыгы.